# 3 нче сыйныф
# татар теле дәресе



# Сорауларга җавап бирегез:


- 1. Фигыль нәрсәне белдерә?
- 2. Нинди сорауларга җавап бирә?
- 3. Фигыльнең юклык формасы ничек ясала?
- 3. Фигыльләр ничә заманда килә?
- 4. Фигыль заманнарын әйтегез.

5. Фигыль тагын нәрсәләр белән төрләнә?

# Рәсемнәр өстендә эш.







# Өченче май.
# Сыйныф эше.
# Фигыль темасын кабатлау

# Артык сүзләрне тап.

Көлә, авыр, сайрады,укучы,тәбрикли, эшлиячәк ,чәчәк, җырлый, дәвалый, матур, бара.

# Мәкальләрне укып, фигыльнең барлык һәм юклык формаларын әйтегез.

- Исем кешене бизәми, кеше исемне бизи.
- Телең белән уйлама, эшең белән уйла.
- Төтен карасы китә, намус карасы бетми.
- Калган эшкә кар ява.

# Бирелгән фигыльләрне төрле заманнарда куеп языгыз.

- Көл
- Эзлә
- Башла
- Сөйлә
- Шатлан

## Язганнарыгызны тикшерегез.

- Көл - көлә, көлде, көләчәк
- Эзлә - эзли, эзләде, эзләячәк
- Башла – башлый, башлады, башлаячак
- Сөйлә - сөйли, сөйләде, сөйләячәк
- Шатлан – шатлана, шатланды, шатланачак

# Ял итеп алыйк әле.

- 1. Ил кайчан филгә әйләнә?
- 2. Ипи башында, ахырында нәрсә килә?
- 3. Гаяз башында нәрсә бар?
- 4. Акыл сүзендәге 2 нче иҗекнең сузык аваз хәрефе.
- 5. Авылда бар, шәһәрдә юк.
- 6. Табигать ахырында нәрсә бар?

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| ф | и | г | ы | л | ь |

Бирелгән җөмләләрдә фигыльләрне табып языгыз.

**Менә яз җитә. Бакчаларда эш кайный. Без мәктәп бакчасында былтыр зур уңыш җыеп алдык. Быел да зур уңыш җыеп алырбыз.**

# Күзләрне ял иттерү

# Дәреслек белән эш.

## 221 нче күнегү

# Рәсем белән эш



**1. Фигыль нәрсәне белдерә?**

а) предметны;

ә) предметның билгесен;

б) предметның эш – хәрәкәтен белдерә.

**2. Фигыльнең юклык формасына нинди кушымчалар ялганып ясала?**

а) – ган, - гән, -кан, -кән;

ә) – ма, - мә;

б) – а, - ә, - ый, - и.

**3. Хәзерге заман хикәя фгыль нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?**

а) - ды, - де, - ты, - те;

ә) – ган, - гән, -кан, -кән;

б) – а, - ә, - ый, - и.

**4. Үткән заман хикәя фгыль нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?**

а) - ды, - де, - ты, - те;

ә) – а, - ә, - ый, - и;

б) – ачак, - әчәк, - ячак, - ячәк.

**5. Киләчәк заман хикәя фгыль нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?**

а) - ды, - де, - ты, - те;

ә) - ачак, - әчәк, - ячак, - ячәк.

б) – а, - ә, - ый, - и;

# Тестны тикшерү.

- 1. б
- 2. ә
- 3. б
- 4. а
- 5. ә

# Өй эше

- 105 бит, 223 нче күнегү (язма)

# Бик зур рәхмәт!
# Булдырдыгыз!